МИНИСТЕРСТВО
ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул.Кремлевская, д.9, г.Казань, 420111

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН
МИНИСТРЛЫГЫ

Кремль ур., 9 нчы йорт, Казан шәһәре, 420111

Тел.: (843) 294-95-90, факс: (843) 292-93-51, e-mail: Minobr.Priemnaya@tatar.ru, сайт: mon.tatarstan.ru

_____№_____

На №_____от_____

**Татарстан Республикасы
муниципаль районнары башкарма
комитетларының мәгариф
идарәләре һәм бүлекләре
җитәкчеләренә**

«Җәлил укулары» әдәби бәйге турында

Хөрмәтле җитәкчеләр!

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы (алга таба – Министрлык) Бөтендөнья татар конгрессы тарафыннан II Халыкара «Җәлил укулары» әдәби бәйгесен үткәрү турында хәбәр итә.

Әлеге чараны уздыруның максатлары булып Россия Федерациясе төбәкләрендә һәм чит илләрдә татар телен, мәдәниятен саклау һәм үстерү, М.Җәлилнең иҗади мирасын популярлаштыру, бөек шагыйрнең иҗатына кызыксынуны арттыру, яшь буынны патриотик рухта тәрбияләү, яшь талантларны ачыклау, аларның сәләтләрен күрсәтүгә мөмкинлекләр тудыру тора.

Югарыда әйтелгәннәрдән чыгып, Министрлык «Җәлил укулары» әдәби бәйгесендә Татарстан Республикасы белем бирү оешмалары укучыларын катнашырга чакыра.

II Халыкара «Җәлил укулары» әдәби бәйгесе нигезләмәсе хатка беркетелгән.

Кушымта: 9 б. 1 н.

Министрның беренче урынбасары **И.Г.Һадиуллин**

И.И.Халиков
(843)294 95 10

«Раслыйм»
Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары,
Бөтендөнья татар конгрессының
Милли Шура рәисе
_____В.Г. Шәйхразиев
«____»_____ 2019 ел

“ҖӘЛИЛ УКУЛАРЫ”
II ХАЛЫКАРА ӘДӘБИ БӘЙГЕСЕ
НИГЕЗЛӘМӘСЕ

2019 ел

Документ создан в электронной форме. № 10792/19 от 30.09.2019. Исполнитель: Халиков И.И.
Страница 2 из 11. Страница создана: 30.09.2019 15:54
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘ

1.1. Нигезләмә “Җәлил укулары” II Халыкара әдәби бәйгесенең (алга таба – бәйге) максатларын һәм бурычларын, шартларын һәм үткәрү тәртибен билгели.

1.2. Бәйге фронтовик язучылар тормышы һәм иҗаты белән кызыксынган шигърият сөючеләр арасында үткәрелә.

2. БӘЙГЕНЕҢ МАКСАТЛАРЫ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ

2.1. Бәйге сөйләм телен үстерү һәм матур әдәбиятка кызыксыну уяту, шигъри сүзнең асылын һәм аһәңен тоярга өйрәнүне максат итеп куя.

2.2. Конкурсның бурычлары:

- Россия Федерациясе төбәкләрендә һәм чит илләрдә татар телен һәм мәдәниятен саклауда, үстерүдә ярдәм итү;
- М.Җәлилнең иҗади мирасын популярлаштыру, фронтовик язучылар иҗатына кызыксынуны арттыру;
- яшь буынны халык традицияләренә җәлеп итү;
- иҗади үсеш өчен шартлар булдыру;
- сәнгатьле уку-башкару осталыгын камильләштерүдә укучыларга шартлар тудыру;
- әдәби иҗатка сәләте булган яшьләрне барлау, таныту һәм сәләтләрен үстерү;
- Әдәби-шигъри әсәрләргә карата уңай эмоциональ мөнәсәбәт тәрбияләү.

3. БӘЙГЕНЕ ОЕШТЫРУ КОМИТЕТЫ

3.1. Бәйгене оештыручылар:

“Бөтендөнья татар конгрессы” регионара иҗтимагый оешмасы;

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы;

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы;

“Татарстан – яңа гасыр” телерадиокомпаниясе;

Татарстан Республикасы Милли китапханәсе;

Татарстан Республикасы Язучылар берлеге;

Татарстан Республикасы Милли музее.

3.2. Бәйгене “Бөтендөнья татар конгрессы” регионара иҗтимагый оешмасы, ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы, ТР Мәдәният министрлыгы, “Татарстан – Яңа гасыр” телерадиокомпаниясе, ТР Милли китапханәсе, ТР Язучылар берлеге, ТР Милли музее вәкилләреннән, мәдәният һәм сәнгать эшлеклеләреннән, татар теле һәм әдәбияты укытучыларыннан торган комитет оештыра (алга таба – **Оештыру комитеты**).

Документ создан в электронной форме. № 10792/19 от 30.09.2019. Исполнитель: Халиков И.И.
Страница 3 из 11. Страница создана: 30.09.2019 15:54
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

3.3. **Оештыру комитеты** Бәйгенең Жюри составын раслый. Жюрига язучылар, актерлар, режиссерлар, әдәбиятчылар, җәмәгать, мәдәният һәм сәнгать эшлеклеләре, татар теле һәм әдәбияты укытучылары, “Бөтендөнья татар конгрессы” регионара иҗтимагый оешмасы вәкилләре керә.

3.4. РФ төбәкләрендә, чит илләрдә Бәйге үткәрүне татар иҗтимагый оешмалары үз өстенә ала.

3.5. Бәйгенең жюри составын РФ төбәкләрендә һәм чит илләрдә татар иҗтимагый оешмалары кураторлары раслый. Жюрига язучылар, актерлар, режиссерлар, әдәбиятчылар, җәмәгать, мәдәният һәм сәнгать эшлеклеләре, татар теле һәм әдәбияты укытучылары, “Бөтендөнья татар конгрессы” регионара иҗтимагый оешмасы вәкилләре керә.

3.6. Бәйгене оештыручы татар иҗтимагый оешмалары координаталарын рәсми сайтта (**http://tatar-congress.org**) һәм Бәйгенең социаль челтәрләрдәге рәсми битләрендә (**https://www.instagram.com/jalil_uku/**, **https://vk.com/jaliluku**) урнаштыра.

4. БӘЙГЕ НОМИНАЦИЯЛӘРЕ

4.1. Бәйге номинацияләре:

М.Җәлил татар телендә;

М.Җәлил рус телендә;

М.Җәлил дөнья халыклары телендә;

Фронтовиклар татар телендә;

Фронтовиклар рус телендә;

Фронтовик язучылар әсәрләрен күмәк башкару;

Яшь җәлилчеләр.

“Җәлил татар телендә” номинациясе

Муса Җәлилнең бер әсәре (тулысынча яки өзек) татар телендә тәкъдим ителергә тиеш. Башкару вакыты – 5 минутка кадәр.

Бәяләү критерийлары:

- башкару осталыгы;
- сайланган әсәрнең укучы яшенә туры килүе;
- текстның мәгънәви тирәнлегенә төшенү;
- чыгыш вакытында музыкаль бизәлеш, декорацияләр, костюмнар файдаланырга мөмкин;

Документ создан в электронной форме. № 10792/19 от 30.09.2019. Исполнитель: Халиков И.И.
Страница 4 из 11. Страница создана: 30.09.2019 15:54
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

• чыгышны бәяләгәндә музыкаль бизәлеш, декорацияләр һәм костюмнар куллану исәпкә алынмый;

• һәр катнашучы үзе генә чыгыш ясый һәм чыгыш барышында башка затларны катнаштыра алмый.

“Җәлил рус телендә” номинациясе

Муса Җәлилнең бер әсәре (тулысынча яки өзек) рус телендә тәкъдим ителергә тиеш. Башкару вакыты – 5 минутка кадәр.

Бәяләү критерийлары:

• башкару осталыгы;

• сайланган әсәрнең укучы яшенә туры килүе;

• текстның мәгънәви тирәнлегенә төшенү;

• чыгыш вакытында музыкаль бизәлеш, декорацияләр, костюмнар файдаланырга мөмкин;

• чыгышны бәяләгәндә музыкаль бизәлеш, декорацияләр һәм костюмнар куллану исәпкә алынмый;

• һәр катнашучы үзе генә чыгыш ясый һәм чыгыш барышында башка затларны катнаштыра алмый.

“Җәлил дөнья халыклары телендә” номинациясе

Муса Җәлилнең бер әсәре (тулысынча яки өзек) дөнья халыклары телендә (татар һәм рус телләреннән тыш) тәкъдим ителергә тиеш. Башкару вакыты – 5 минутка кадәр.

Бәяләү критерийлары:

• башкару осталыгы;

• сайланган әсәрнең укучы яшенә туры килүе;

• текстның мәгънәви тирәнлегенә төшенү;

• чыгыш вакытында музыкаль бизәлеш, декорацияләр, костюмнар файдаланырга мөмкин;

• чыгышны бәяләгәндә музыкаль бизәлеш, декорацияләр һәм костюмнар куллану исәпкә алынмый;

• һәр катнашучы үзе генә чыгыш ясый һәм чыгыш барышында башка затларны катнаштыра алмый.

“Фронтовиклар татар телендә” номинациясе

Фронтовик язучының (бәйгедә катнашучының якташы булуы мөһим) бер әсәре (тулысынча яки өзек) татар телендә тәкъдим ителергә тиеш. Башкару вакыты – 5 минутка кадәр.

Документ создан в электронной форме. № 10792/19 от 30.09.2019. Исполнитель: Халиков И.И.
Страница 5 из 11. Страница создана: 30.09.2019 15:54
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

Бәяләү критерийлары:

- башкару осталыгы;
- сайланган әсәрнең укучы яшенә туры килүе;
- текстның мәгънәви тирәнлегенә төшенү;
- чыгыш вакытында музыкаль бизәлеш, декорацияләр, костюмнар файдаланырга мөмкин;
- чыгышны бәяләгәндә музыкаль бизәлеш, декорацияләр һәм костюмнар куллану исәпкә алынмый;
- һәр катнашучы үзе генә чыгыш ясый һәм чыгыш барышында башка затларны катнаштыра алмый.

“Фронтовиклар рус телендә” номинациясе

Фронтовик язучының (бәйгедә катнашучының якташы булуы мөһим) бер әсәре (тулысынча яки өзек) рус телендә тәкъдим ителергә тиеш. Башкару вакыты – 5 минутка кадәр.

Бәяләү критерийлары:

- башкару осталыгы;
- сайланган әсәрнең укучы яшенә туры килүе;
- текстның мәгънәви тирәнлегенә төшенү;
- чыгыш вакытында музыкаль бизәлеш, декорацияләр, костюмнар файдаланырга мөмкин;
- чыгышны бәяләгәндә музыкаль бизәлеш, декорацияләр һәм костюмнар куллану исәпкә алынмый;
- һәр катнашучы үзе генә чыгыш ясый һәм чыгыш барышында башка затларны катнаштыра алмый.

“Фронтовик язучылар әсәрләрен коллектив белән башкару” номинациясе

Фронтовик язучының бер әсәре (тулысынча яки өзек) татар яки рус телләрендә коллектив (2 дән 10 кешегә кадәр) белән тәкъдим ителергә тиеш. Башкару вакыты – 5 минутка кадәр.

Бәяләү критерийлары:

- башкару осталыгы;
- сайланган әсәрнең укучы яшенә туры килүе;
- текстның мәгънәви тирәнлегенә төшенү;
- чыгыш вакытында музыкаль бизәлеш, декорацияләр, костюмнар файдаланырга мөмкин;
- чыгышны бәяләгәндә музыкаль бизәлеш, декорацияләр һәм костюмнар куллану исәпкә алынмый.

Документ создан в электронной форме. № 10792/19 от 30.09.2019. Исполнитель: Халиков И.И.
Страница 6 из 11. Страница создана: 30.09.2019 15:54
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

“Яшь җәлилчеләр” номинациясе

Бөек Ватан сугышы (сугыш чоры вакыйгалары, фронтовиклар, тылдагы тормыш һ.б.) турында катнашучы татар яки рус телләрендә үзе иҗат иткән бер әсәр (шигырь, поэма, эссе, хикәя һ.б.) тәкъдим ителергә мөмкин. Башкару вакыты – 5 минутка кадәр.

Бәяләү критерийлары:

• Теманың тулысынча ачылуы; әсәрнең композициясе; стилистик үзенчәлекләре; тасвирлап бирү осталыгы; оригинальлек; әдәби жанр үзенчәлекләрен куллана белү; шигырь язу кануннарын белү һәм куллану;

• башкару осталыгы;

• текстның мәгънәви тирәнлегенә төшенү;

• чыгыш вакытында музыкаль бизәлеш, декорацияләр, костюмнар файдаланырга мөмкин;

• чыгышны бәяләгәндә музыкаль бизәлеш, декорацияләр һәм костюмнар куллану исәпкә алынмый.

5. БӘЙГЕНЕ ҮТКӘРҮ ТӘРТИБЕ

5.1. Бәйгедә катнашу бушлай.

5.2. Катнашучыларның рөхсәт ителгән яше: 4 яшьтән 25 яшькә кадәр.

5.3. Бәйге номинацияләрендә яшь төркемнәре һәм категорияләре:

• 4 яшьтән 8 яшькә кадәр (кертеп);

• 9 яшьтән 13 яшькә кадәр (кертеп);

• 14 яшьтән 17 яшькә кадәр (кертеп);

• 18 яшьтән 25 яшькә кадәр (кертеп).

5.4. Бәйге һәр ел, алдан сайлап алуларсыз, барлык катнашырга теләүчеләр өчен үткәрелә. Бәйгедә катнашудан баш тарту, шулай ук бәйгедә катнашырга мәҗбүр итү тыела.

5.5. Катнашучы тарафыннан бәйге кагыйдәләре тиешенчә үтәлмәгән очракта, Оештыручы алга таба аны бәйгедә катнаштырмаска мөмкин.

5.6. Бәйге 4 этапта үткәрелә:

1 нче этап – сайлап алу турлары:

• Оештыру комитеты билгеләгән вакытка кадәр, җирле Оештыру комитетлары Татарстан Республикасының һәр муниципаль районында, Россия Федерациясе регионнарында, Якын һәм Ерак чит илләрдә үткәрә. Катнашучыларны сайлап алуны җирлекләрдә оешкан Җюри билгели;

Документ создан в электронной форме. № 10792/19 от 30.09.2019. Исполнитель: Халиков И.И.
Страница 7 из 11. Страница создана: 30.09.2019 15:54
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН